**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ УРКУШСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ КУКМОРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ КУКМАРА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ ӨРКЕШ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

---

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2023 нче елның 7нче апреленән №27

Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районының "Өркеш авыл җирлеге" муниципаль берәмлеге территориясендә терегөмөшле лампалар туплану урынын (урыннарын) булдыру, кулланучыларга аның (аларның) урнашуы турында мәгълүмат бирү турында

«Җитештерү һәм куллану калдыклары турында» 1998 елның 24 июнендәге 89-ФЗ номерлы, «Әйләнә-тирә мохитне саклау турында» 2002 елның 10 гыйнварындагы 7-ФЗ номерлы, «Энергияне сак тоту һәм энергетик нәтиҗәлелекне арттыру һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү хакында» 2009 елның 23 ноябрендәге 261-ФЗ номерлы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законнар, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы, «Тиешенчә булмаган җыю, туплау, куллану, зарарсызландыру, транспортлау һәм урнаштыру гражданнарның тормышына, сәламәтлегенә, хайваннарга, үсемлекләргә һәм әйләнә-тирә мохиткә зыян китерергә мөмкин яктырту җайланмалары, электр лампалары өлешендә җитештерү һәм куллану калдыклары белән эш итү кагыйдәләрен раслау турында» Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2020 елның 28 декабрендәге 2314 номерлы карары нигезендә карар бирәм:

1. Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Кукмара шәһәре ( Өркеш авыл җирлеге) территориясендә эштән чыгарылган терекөмешле лампалар туплау урынын (урыннарын) билгеләргә: Татарстан Республикасы, Кукмара районы, Югары Арбаш авылы, Яшел урам, йорт:104а

2. Күп фатирлы йортларның милекчеләре, яллаучылары, кулланучылары булган терекөмешле лампалар кулланучыларның эштән чыгарылган терекөмешле лампаларын туплау урыннары Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2020 елның 28 декабрендәге 2314 номерлы карары белән расланган Тиешенчә булмаган җыю, туплау, куллану, зарарсызландыру, транспортлау һәм урнаштыру гражданнарның тормышына, сәламәтлегенә, хайваннарга,

үсемлекләргә һәм әйләнә-тирә мохиткә зыян китерергә мөмкин яктырту җайланмалары, электр лампалары өлешендә җитештерү һәм куллану калдыклары белән эш итү кагыйдәләренең 4 пункты нигезендә билгеләнә.

3. Әлеге карарның 1 пунктында күрсәтелгән эштән чыгарылган терекөмешле лампаларны туплау урыннары, әлеге күп фатирлы йортларда туплау урыннарын оештыру өчен биналар булмау сәбәпле, эштән чыгарылган терекөмешле лампаларны туплау урыннарын оештыру мөмкин булмаган очракта, шул исәптән күп фатирлы йортларның милекчеләре, яллаучылары, кулланучылары булган терекөмешле лампаларны кулланучылар өчен дә билгеләнгән дип билгеләргә.

4. Кулланучыларга Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Кукмара шәһәре ( Өркеш авыл җирлеге) территориясендә эштән чыгарылган терекөмешле лампалар туплау урынының (урыннарының) урнашкан җире турында мәгълүматны Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районының рәсми сайтында,Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Кукмара шәһәре (Өркеш авыл җирлеге) җирле үзидарә органнары биналарында мәгълүмати стендларда (стойкаларда) урнаштыру юлы белән хәбәр итәргә.

5. Әлеге карарны авыл җирлеге территориясендә урнашкан мәгълүмат стендларында, Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында игълан итәргә (pravo.tatarstan.ru), шулай ук Кукмара муниципаль районының рәсми сайтында Интернет мәгълүмати-коммуникацион челтәрендә урнаштырырга.

6. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Кукмара шәһәре ( Өркеш авыл җирлеге) башкарма комитеты җитәкчесенә калдырырга.

Өркеш авыл җирлеге
башкарма комитеты җитәкчесе: А.Ш.Әгъләмова